**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАЛЫКЛЫ-ЧУКАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**

**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422655, с. Балыклы-Чукаево,

ул. Центральная, дом 8

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**БАЛЫК БИСТӘСЕ**

**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**БАЛЫКЛЫ-ЧҮКӘЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422655, Балыклы-Чүкәй,

Үзәк урамы, 8 нче йорт,

Тел.: (84361) 26357, факс: (84361) 26357, e-mail12Blc.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 25 июле** **Балыклы-Чүкәй ав** **№ __16___**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең 2017 елның 16 ноябрендәге 18 номерлы карары белән расланган 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга яраклаштыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, шәһәр округларының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» 2015 елның 1 октябрендәге 1050 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, карар бирәм::

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 16 ноябрендәге 11 номерлы карары белән расланган 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына (2018 елның 28 мартындагы 2 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

программа паспортында:

1.1) 7 юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле 8 юл өстәргә: «халыкны социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин итүнең максатчан күрсәткечләре (Индикаторлары)»:

| | |
|---|---|
| "Социаль инфраструктура объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү буенча планлаштырылган чараларның (инвестицион проектларның) киңәйтелгән тасвирламасы | 1. Балыклы-Чүкәй авылы мәктәбендә капиталь ремонт;<br>2. Иске Арыш авылында капиталь ремонт;<br>3. Балыклы-Чүкәй авылында 100 урынга исәпләнгән Мәдәният йортына капиталь ремонт;<br>4. Балыклы-Чүкәй авылында универсаль спорт мәйданчыгы төзелеше;<br>5. Балыклы-Чүкәй авылында ФАП төзелеше. |

1.2) 8-10 юлларны 9-11 юллар белән санарга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең Балыклы-Чүкәй авылы, Үзәк урамы, 8 йорт; Иске Арыш авылы, Үзәк урамы урамы, 23А йорт, Керәшен Казысы авылы, Титов Урамы, 11б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы Чүкәй авыл җирлеге
Башлыгы А.М.Нуретдинова